**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы советы КАРАРЫ**

**2019 елның 20 нроября** **№ 233**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны гамәлгә ашыруның барышы хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2019 елның 18 июнендәге 2931-V ДС номерлы Карарының 5 пунктын үтәүдә, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 2 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г. Ә. Габидуллин чыгышын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР чыгарды.:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә. Габидуллин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетына, Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

2.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне алга таба камилләштерү буенча чаралар күрергә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында законнарда билгеләнгән таләпләрнең, шул исәптән керә торган мөрәҗәгатьләрне мәҗбүри теркәү өлешендә, аларны карау срокларын һәм нәтиҗәлелеген, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру өлешендә, тайпылышсыз үтәүне контрольдә тотуны көчәйтергә;

2.2. Кирәк булганда гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне регламентлаучы, шул исәптән үз вакытында җавап бирү юнәлешен раслаучы документларның сакланышын тәэмин итүне күздә тотучы норматив хокукый актларны кабул итүне тәэмин итәргә кирәк;

2.3. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә системалы рәвештә кварталга кимендә бер тапкыр анализ ясарга һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны бозу фактларын бетерү буенча чаралар күрергә;

2.4. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда башкару дисциплинасы дәрәҗәсен күтәрергә, кирәк булганда, бу өлкәдә закон бозган затларга карата хезмәт тикшерүләре үткәрергә кирәк;

2.5. Гражданнарны кабул итүне оештыруның законнарда каралган барлык рәвешләрен активрак кулланырга;

2.6. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә вәкаләтле белгечләрнең һөнәри квалификациясен күтәрүне вакытында тәэмин итәргә.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне активлаштыру максатында, Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутатларына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауны исәпкә алып, җирле үзидарәнең вәкиллекле органына сайланган җирлекләрдә гражданнарны даими кабул итүне оештырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль район**
**Советы рәисе** **Н. А. Вазыйхов**